**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 сентябрендәге 3099 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 27 апрелендәге 1284 номерлы «Казан шәһәре территориясендә сезонлы тематик ярминкәләрне оештыру планын һәм урнаштыру схемасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәрендә ярминкәләр уздыру урыннарының үзгәрүенә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1284 номерлы «Казан шәһәре территориясендә сезонлы тематик ярминкәләрне оештыру планын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1513 номерлы, 2020 елның 17 сентябрендәге 2621 номерлы, 2020 елның 25 сентябрендәге 2713 номерлы, 2020 елның 5 ноябрендәге 3170 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 3759 номерлы, 2021 елның 26 апрелендәге 1010 номерлы, 2021 елның 9 июнендәге 1442 номерлы, 2021 елның 2 сентябрендәге 2174 номерлы, 2021 елның 15 октябрендәге 2653 номерлы, 2021 елның 21 октябрендәге 2743 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 3374 номерлы, 2022 елның 25 маендагы 1513 номерлы, 2022 елның 1 ноябрендәге 3750 номерлы, 2023 елның 1 мартындагы 609 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге

2883 номерлы, 2024 елның 1 июлендәге 2751 номерлы, 2025 елның 3 июлендәге 2072 номерлы карарлары белән кергән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле 96-98 юллар өстәргә:

| № т/б | Ярминкә нең төре | Төре оештыручы | Үткәрү вакыты | Урнашкан урыны . | Урын нар саны | Мәйданы, квадрат метрларда | Ярминкәне оештыручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «96 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Беломорск урамы, 6 йорт (Авиатөзүчеләр районы) | 25 кә кадәр | 1360 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3 йорт) |
| 97 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Симонов урамы, 17 йорт Авиатөзүчеләр районы | 70 кә кадәр | 3150 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3 йорт) |
| 98 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Ә.Авзалова урамы, 15 йорт (Киров районы) | 50 гә кадәр | 1000 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3 йорт) |

1.2. 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә редакцияләнгән схема белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
**Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 сентябрендәге**
**3099 номерлы карарына**
**кушымта**

**Казан шәһәре территориясендә сезонлы тематик ярминкәләрне урнаштыру схемасы**

Беломорск урамы, 6 йорт, мәйданы – 1360 кв.м (25 урынга кадәр)




Симонов урамы, 17 йорт, мәйданы – 3150 кв.м (70 урынга кадәр)



Ә.Авзалова урамы, 15 йорт, мәйданы – 1000 кв.м (50 урынга кадәр)

